БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«07» 05 2026 ел

**КАРАР**

№ 176

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләме турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 168 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренә җирле бюджеттан финанслана торган командировка чыгымнарына бәйле чыгымнарны түләүне тәртипкә китерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле командировка чыгымнарын каплау тәртибе һәм күләмнәре турында» 2019 елның 30 декабрендәге 402 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктның а пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) торак урынга наем чыгымнарын (хезмәт командировкасына җибәрелгән хезмәткәр түләүсез урнаштырылган очрактан тыш) - бер бүлмәле (бер урынлы) номерның бәясеннән артмаган тиешле документлар белән расланган факттагы чыгымнар күләмендә, ләкин 2500 сумнан артык түгел;»

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгына Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренең командировка чыгымнарын кайтарганда әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Нигезләмәгә һәм гамәлдәге законнарга таянырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов